**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МОРДОВСКО-АФОНКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**МОРДВА АФОНЬКӘСЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул., 19 дом

423103, Мордва Афонькәсе авылы, Цаплин урамы, 19нче йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru:

# КАРАР
# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

22 май 2019 ел №8

**2019 елның җәйге чорында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең су объектларында бәхетсезлек очракларын булдырмау чаралары турында**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең тормышын саклау максатларында 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау Кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары белән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 7 августындагы 577 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән расланган Россия Федерациясе Су кодексының 7 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» һәм Татарстан Республикасы территориясендә суда кешеләр тормышын саклау Кагыйдәләре» Федераль законның 14 статьясы нигезендә, ТР Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Уставына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 1 июненә кадәр Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты бюджеты хисабына су коенуны тыю билгеләрен әзерләргә һәм су объектының яр буе өлешендә куярга. Тыю билгеләре яклары кимендә 50-60 см үлчәмле турыпочмак формасында була һәм такталардан, калын фанерадан, металл битләрдән яки башка ныклы материалдан әзерләнә. Билгеләр күренеп торган урыннарда урнаштырыла һәм нигезе җиргә

күмелгән баганаларда (агач, металл, тимер-бетон һ.б.) ныгытыла. Баганаларның җир өстеннән биеклеге 2,5 метрдан да ким булмаска тиеш. Билгеләрдәге язулар кара яки ак буяу белән (тукыма (полотно) фонынннан чыгып) ясала.

2. Суда кешеләрнең тормышын саклау Кагыйдәләре нигезендә, техник тикшерү узмаган һәм җиһазландырылмаган су коену урыннарында су коену тыюларының үтәлешен контрольдә тотуны көчәйтергә. Исерек килеш суда коенучы яки сулыклар буенда спиртлы эчемлекләр эчүче затларны административ җаваплылыкка тарту чараларын күрергә.

3. Санитар кагыйдәләрнең үтәлешен һәм эпидемиягә каршы санитар (профилактик) чаралар үткәрүне тикшереп торырга.

4. Түбәндәге составта мобиль патруль төркем составын расларга:

- Авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары Ф.Ю. Павлов;
- «Лагерканың гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры А.П. Майоров;
- "Мордва Афонькәсе мәдәният йорты" МБУ сәнгать җитәкчесе Е.Г. Матвеева.
- Мордва Афонькәсе авылында Үзәк җирлекара китапханә филиалы китапханәчесе В.И. Семкичева;

2019 елның 1 июненнән, июльдә һәм 15 августына кадәр коену урыннарында патрульлек итү өчен, дежур тору графигын раслап.

5. Авыл җирлеге территориясендә урнашкан сулыкларда бәхетсезлек очракларын кисәтү буенча халык арасында агитация чаралары (әңгәмәләр, җирле халык җыеннары һ.б.) кулланып профилактик эш оештыру.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

7. Карар кул куелганнан бирле үз көченә керә.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе А.И. Митяев